ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2023 Олы Кайбыч ав. № 157

Кайбыч муниципаль районында 2022-2023 елгы ягу сезонын тәмамлау һәм 2023-2024 елның көзге-кышкы чорында җылыту сезонына әзерлек турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 06 маендагы 354 номерлы карары нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы Цельсий буенча 8 градустан артык булу сәбәпле һәм торак-коммуналь хуҗалык, ягулык-энергетика комплексы предприятиеләрен һәм социаль-мәдәни көнкүреш объектларын 2023 - 2024 еллар җылыту сезонына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга:

1.1. 2022 - 2023 елның 24 апреленнән ягулык сезонын тәмамларга.

1.2.Котельныйларда, үзәк җылылык пунктларында, тышкы челтәрләрдә һәм эчке инженерлык системаларында һәм кайнар су белән тәэмин итүдә ремонт һәм профилактика эшләренә көзге-кышкы чорда эшләргә әзерлек чаралары нигезендә әзерләнергә тәкъдим итәргә.

2. Объектларны 2023-2024 елның көзге-кышкы чорында эшләргә әзерләүне 2023 елның 15 сентябренә төгәлләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 24 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р. Сәләховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров